ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2021 п.г.т.Алексеевское № 443

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы башкарма
комитетының резерв фондыннан бюджет
ассигнованиеләреннән файдалану турындагы
Нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 маддәсендәге 6 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының резерв фондыннан бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар, 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеттан башлап, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 10 декабрендәге
443 номерлы карарына
кушымта

**Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында**
**Нигезләмә**

1. Алексеевск районы башкарма комитетының резерв фонды күләме Алексеевск муниципаль районы Советы карары белән чираттагы финанс елына Алексеевск муниципаль районы бюджетын раслаганда билгеләнә һәм район бюджеты чыгымнарының 3 (өч) процентыннан арта алмый.

2. Резерв фонды акчалары район һәм республика масштабларында социаль-икътисадый тигезлекне саклап калу өчен көтелмәгән чыгымнарны финанслауга тотыла:

а) стихияле бәла-казалар һәм агымдагы финанс елында урыны булган башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү буенча авария-торгызу эшләре башкару;

б) стихияле бәла-казаларны һәм башка гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чараларын үткәрү;

в) урыннарда да, район һәм республикадан читтә дә хокук тәртибен саклау буенча соңгы федераль, төбәк һәм район программаларын гамәлгә ашырганда хокук саклау органнарына һәм аларның хезмәткәрләренә финанс ярдәме күрсәтү;

е) халык иҗатын, фольклорын үстерү һәм талантларны саклап калу өчен финанс ярдәме күрсәтү;

ж) стихияле бәла-казалар, янгыннар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга финанс ярдәме күрсәтү;

з) социаль әһәмиятле, мәдәни объектлар, инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен торак төзүне, капиталь ремонтлауны өлешчә финанслау;

и) иҗтимагый оешмаларга өлешчә финанс ярдәме (инвалидлар - әфганчылар һәм башкалар);

й) ел дәвамында гомумдәүләт, республика, район программаларын һәм карарларын финанслауны финанслау.

3. Резерв фонды акчаларын тоту Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты күрсәтмәләре һәм карарлары нигезендә башкарыла.

4. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының резерв фонды акчаларыннан файдалану турындагы хисап бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапка кушымта итеп бирелә.

**Башкарма комитет**
**эшләре идарәчесе** **Г.Ә.Йосыпова**